
Ин топ шарт - районнарда һәм тобәк башкаласында жылылык белән тәэмин итv системасы ышанычлы булырга тиеш.
Нәкъ менә шуна кvрә елдан-ел челтәрләрне модернизацияләvгә аерым игътибар бирелә. 2023 елда мәсьәләгә бик житди карадылар: ресурслар белән тәэмин итvче компания узган ел белән чагыштырганда ике тапкыр Саранскны кышка жылылык белән тәэмин итv системасын әзерләvгә финанслауны арттырды.       Регионыбызда киләсе жылыту сезонына әзерлек актив алып барыла, дидек. Мордовиянен региональ энергетика һәм ЖКХ министрлыгынын матбугат хезмәтендә жылылык челтәрләрендә башкарылган эшләр турында хәбәрләр бар.
Ведомство мәгълvматлары буенча, 2023 елда жылылык белән тәэмин итvчеләр челтәрләрне һәм жылылык белән тәэмин итv объектларын реконструкцияләvгә 1,2 миллиард сумнан артык акча жибәрәчәк. Финанслау ярдәмендә 25 километр жылыту торбалары һәм ике километр кайнар су белән тәэмин итv торбалары алыштырылган. Алар урынына герметик тышчада изоляцияле яна тимер торбалар салу дәвам итә. Алар дистанцион контроль системасы белән жиһазландырылган.
Әмма яшәv тораклары яны тулысынча ремонтлап бетмәгән. Анда-монда теплотрассанын торбаларын алмаштыру дәвам итә. Коз быел безне шатландырып тора. Шуна да салкыннар житкәнче барлык эшләр тәмамланыр дип уйларга урын бар.
Искәрмә. Биналарны жылыту сезоны уртача тәvлеклек урам температурасынын 5 тәvлек дәвамында +8 градуска кадәр тошvе белән башлана. Беренче чиратта мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, медицина учреждениеләрендә, ә аннары кvп фатирлы йортларда башлана. Сонгы чиратта жылытуны сәнәгать биналарында кертәләр.

**Н.ХӘЛИЛ**